Башкарма комитет – муниципаль район (шәһәр округы) башкарма комитеты;
ГХАТ БДР – гражданлык хәле актларын теркәү Бердәм дәүләт реестры;
ЕГИССО – социаль тәэмин итүнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы.
Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза (алга таба - гариза) дигәндә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 2 статьясындагы 3 пункты нигезендә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запрос аңлашыла.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

### 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме

Каникул вакытында балаларның ялын оештыру

### 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтә торган җирле үзидарә башкару - боеру органының исеме

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы башкарма комитеты (Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе, ТР Тукай муниципаль районы «Балкыш» балалар сәламәтләндерү лагере» муниципаль бюджет учреждениесе, «ТР Тукай муниципаль районының яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» муниципаль бюджет учреждениесе, «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган Бәтке УГББМ» МБГББУ, «Биклән УГББМ» МБГББУ, «Боерган УГББМ» МБГББУ, «Борды УГББМ» МБГББУ, «Иштирәк УГББМ» МБГББУ, «Калмаш УГББМ» МБГББУ, «Калмия УГББМ» МБГББУ, « Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган Князево УГББМ» МБГББУ, «Комсомолец УГББМ» МБГББУ, «Күзкәй УГББМ» МБГББУ, «Кече Шилнә УГББМ» МБГББУ, «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган Мәләкәс УГББМ» МБГББУ, «Мусабай-Завод УГББМ» МБГББУ, «Түбән Суыксу УГББМ» МБГББУ, «Яңа Троицкий УГББМ» МБГББУ, «Сәмәкәй УГББМ» МБГББУ, «Яңа пос. УГББМ» МБГББУ, «Круглое Поле УГББМ» МБГББУ, «Иске Абдул УГББМ» МБГББУ, «Иске Дөреш БГББМ» МБГББУ, « Теләнче-Тамак УГББМ» МБГББУ, «Инглиз теле тирәнтен өйрәнелә торган Шилнәбаш УГББМ» МБГББУ, «Яңа Бүләк ТГББМ» МБГББУ).

### 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау

2.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып тора:
1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында карар (әлеге Регламентка 1 нче кушымта);
2) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар (әлеге Регламентка 2 нче кушымта).

